**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләченең беренче номерлы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе**

Раслыйм
Теләченең беренче балалар бакчасы мөдире
__________ /Давлетшина А.Н/
Балалар бакчасының педагоглар киңәшмәсендә каралды. Беркетмә №1.
Приказ № 94 28.08.2023 ел.

# 2023-2024 уку елына рус балаларын татар теленә өйрәтү буенча эш программасы

Татар теле тәрбиячесе
Сабирзянова Л.М

2023-2024 уку елы

## ЭЧТӘЛЕК.


| **1.Программаның максатчанлык бүлеге** | |
|---|---|
| 1.1. Аңлатма язуы | 2 |
| 1.1.1. Эш программасының максаты һәм бурычлары | 3 |
| 1.1.2. Эш программасының принциплары | 3 |
| 1.2. Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр | 4 |
| 1.3. Диагностик матераллар | 4 |
| **2. Программаның эчтәлек бүлеге** | 6 |
| 2.1. Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге. | 6 |
| 2.2. Балаларны Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә туры китереп татар теленә өйрәтү. | 7 |
| 2.3. Программаны гамәлгә кертү һәм үзләштерү буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеген оештыру | 7 |
| 2.4. Ата- аналар белән эш. | 8 |
| **3. Программаның оештыру бүлеге.** | 9 |
| 3.1. Баланың үсеше өчен психолого-педагогик шартлар | 9 |
| 3.2. Предметлы-үстерелешле әйләнә тирәлек | 12 |
| 3.4. Материаль - техник тәэмин ителү | 12 |
| 3.6. Белем бирү эшчәнлеген оештыру. | 15 |
| 3.7. Көн тәртибе | 22 |
| 3.9. Норматив-методик документлар | 23 |
| 3.10.Кулланылган әдәбият исемлеге | 24 |


**Балалар бакчасында рус телле балаларны**
**татарчага өйрәтү программасы.**

### 1. АҢЛАТМА ЯЗУЫ.

Теләченең беренче номерлы балалар бакчасында рус телле балаларны татар теленә өйрәтү программасын татар теле тәрбиячесе Сабирзянова Л.М. төзеде.

Балалар бакчасында татар теленә өйрәтү программасы түбәндәге норматив документларга нигезләнде:

**Федераль җирлегендә:**

- 29.12.2012 елдан № 273-ФЗ « Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;
- СанПиН 2.4.1.3049-13 « Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр" раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2013 ел 15 май 26 нчы номырлы боерыгы;

**Төбәк җирлегендә:**

- Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында" Законы;
- Шаехова Р.К **"Сөенеч"** төбәкара мәктәпкәчә белем бирү программасы. – РИЦ,2016.

**Мәктәпкәчә белем учреждениесе җирлегендә:**

- МБМБУ Уставы;
- МБМБУнең төп белем бирү программасы турында программага таянып эшләнде.

Мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем стандартларын күздә тотып, укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде,1 сентябрьдән 31 майга кадәр вакытны үз эченә ала.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтүне чагылдыра. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың яшь үзенчәлекләренә, методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

**1.Программаның максатчанлык бүлеге**

**Эш программасының максаты һәм бурычлары**

**1.1.1. Максат:** Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

**Бурычлар:** 1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү.
3. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү.
4.Татар телен белү һәм сөйләшү теләге уяту.

**Милли – төбәк компонентын өйрәтү буенча бурычлар:**

1. Туган як,туган ил ,анда яшәүче халыклар һәм гореф – гадәтләре, табигате турында белемнәрен үстерү .
2. Туган телгә кызыксыну ,үз туган телендә аралашу теләге уяту.
3. Идел буе халыкларның тормыш-көнкүреше һәм сәнгате белән таныштыру.

**1.1.1. Татарча сөйләшергә өйрәткәндә куелган минимум бурычлар.**

Программа өч проектны һәм аларның төп максатларын һәм бурычларын үз эченә ала:

- **“Минем өем” проекты (4-5 яшь).**

Максат: Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар:
1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.
2. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.
3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

- **“Уйный – уйный үсәбез” проекты (5-6 яшь).**

Максат: Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

Бурычлар:
1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

- **“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты (6-7 яшь).**

Максат: Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

Бурычлар:
1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**1.1.2. Программа принциплары.**

*Коммуникативлылык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.

*Интеграция һәм дифференциация принцибы* – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;

*Күрсәтмәлелек принцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;*

*Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы:* социаль-аралашу, танып-белү, сөйләм үсеше, нәфис-нәффәсати, физик культура

*Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

*Белем бирүне комплексы-тематик принципка корып оештыру;*

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне

өйрәтү процессында уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

*Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы* - гадидән катлаулыга таба бару.

*Индивидуальләштерү принцибы* - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

**1.2. Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр.**

- **“Минем өем” проекты. (**4-5яшьлек балалар өчен)

**Лексик минимум** – якынча 62 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.

**Актив сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 сүз)

**Сөйләм үрнәкләре:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз)

**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- гаилә
- ашамлыклар
- уенчыклар
- саннар

- **“Уйный – уйный үсәбез” проекты. (**5-6 яшьлек балалар өчен)

**Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз)

**Сөйләм үрнәкләре:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз).

**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- яшелчәләр
- ашамлыклар
- савыт- саба
- киемнәр
- шәхси гигиена
- өй җиһазлары
- бәйрәм “Туган көн”
- бәйрәм “Сабан туй”
- Уртанчылар төркемендәге темалар(гаилә, ашамлыклар, уенчыклар, саннар) ел дәвамында кабатлана.

- **“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты.**

6-7 яшьлек балалар (мәктәпкә әзерлек төркеме) өчен якынча 60 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.

**Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр, нәрсә яратасың?(пассив сүз)

Проектның эчтәлеге уртанчылар, зурлар төркемендә өйрәнгән сүзләргә таянып аралашуга корылган.

**1.3. Балаларның татар телен аңлау һәм сөйли белү дәрәҗәләрен билгеләү.**

**Уртанчылар төркемендә балаларның татар телен**

**аңлау һәм сөйли белү дәрәҗәләрен билгеләү.**

**4 – 5 яшьлек рус телле балаларның татар телен белү дәрәҗәсен күзәтү**

4-5 яшьлек рус телле балаларның татар телен белү дәрәҗәсен күзәтү һәр бала белән аерым үткәрелә, ул 5 – 10 минуттан артмаска тиеш. Ә йомгаклау дәресе булганда, күзәтү барлык балалар белән бергә үткәрергә мөмкин. Биремнәр уен формасында рус телендә аңлатыла. Балаларның җавабын тыңлаганда, тәрбияче, кирәк булса, җавапны дөресләп, бала әйтә алмаган очракта, булышырга тиеш. Күзәтү нәтиҗәләрен түбәндәгечә таблицага төшерергә мөмкин.

| № | **Балаларның исем, фамилиясе** | **Сүз байлыгы** | | **Бәйләнешле сөйләм** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “ Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексикан ы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча 4-5 рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (исәнме, сау бул, рәхмәт) | Боерыкны аңлап үтәүһәм куллану белү (кил, утыр. ю, сикер. аша, эч) | Тирә- юньдәге предметларның сыйфатын , күләмен белдерә торган сүзләрне сөйләмдә куллану. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү , чакыру, сыйлау, сорап алу, раслау, инкарь итү, тәкъдим итү) |
| 1 | | | | | | |
| 2 | | | | | | |

**Зурлар төркемендә балаларның татар телен белү дәрәҗәсен күзәтү**

5-6 яшьлек рус балаларының татар телен белү дәрәҗәсен күзәтү һәр бала белән аерым үткәрелә, ул 5–10 минуттан артмаска тиеш. Ә йомгаклау дәресе булганда, күзәтүне барлык балалар белән бергә үткәрергә мөмкин. Биремнәруен формасында рус телендә аңлатыла. Аларның җавабын тыңлаганда,тәрбияче , кирәк булса, җавапны дөресләп, бала әйтә алмый торган очракта булышырга тиеш. Күзәтү нәтиҗәләрен түбәндәгечә таблицага төшерергә мөмкин.

| № | **Балаларның исем, фамилиясе** | **Сүз байлыгы** | | **Бәйләнешле сөйләм** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “ Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексикан ы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча 4-5 рәсем яисә | Ягымлы сүзләр куллану (исәнме, сау бул, рәхмәт, исәнмесез, сау булыгыз) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр. ю, сикер. аша, эч, ки, сал) | Уен ситуация-ләрендәүзлектән сорау бирә белү нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү , чакыру, сыйлау, сорап алу, раслау, инкарь итү, тәкъдим итү) |
| 1 | | | | | | |
| 2 | | | | | | |
| 3 | | | | | | |

**Мәктәпкәчә әзерлек төркемендә балаларның татар телен белү дәрәҗәсен күзәтү**

6-7 яшьлек рус телле балаларның татар телен белү дәрәҗәсен күзәтү һәр бала белән аерым үткәрелә, ул 5 –10 минуттан артмаска тиеш. Ә йомгаклау дәресе булганда, күзәтүне барлык балалар белән бергә үткәрергә мөмкин. Биремнәр уен формасында рус телендә аңлатыла. Балаларның җавабын тыңлаганда, тәрбияче, елмаеп, кирәк булса, җавапны дөресли, әгәр бала әйтә алмый торса, аңа ярдәм итә. Күзәтү нәтиҗәләре таблицага языла.

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | Бәйләнешле сөйләм | | | Баллар суммасы | Белем дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “ Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану (өйрәнгән темалар буенча | Ягымлы сүзләр куллану (Исәнме, исәнмесез, сау бул, сау булыгыз, рәхмәт, зур рәхмәт, хәерле көн, хәлләр ничек, әйбәт) | Боера белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, кис, ал, бие, җырла, йөгер, йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү (нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

**2. Эчтәлек бүлеге**

**2.1. Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**

Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге балалар белән эшләү өчен ФДББС, Р. К. Шаехованың “Сөенеч” прграммасы, З. М. Зарипованың укыту –методик комплекты нигезендә балаларны татар телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү, тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау, телне тоемлау сәләте булдыру максатыннан чыгып төзелде. Методик әсбап танып белү, сөйләм үстерү, матур әдәбият белән таныштыру кебек белем бирү өлкәләрен үз эченә ала. Балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота.

Методик кулланмада ФДББС буенча өч белем бирү өлкәсе: танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү), матур әдәбият белән таныштыру карала. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомум кабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспектлары үстерешле белем бирү, белем бирү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала. Дүртенче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Шундый формаларның берсе булып бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таянып үткәрелә. Эшчәнлек төрләрен оештыру федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалаштыруга: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын

үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомум кабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштергән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән бала шәхесе тәрбияләүгә юнәлдерелә.

**2.2.Балаларны Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә туры китереп татар теленә өйрәтү.**

**1. Сөйләм үсеше**.

Сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру.

**2. Социаль- коммуникатив үсеш**

Социаль күренешләр (үзең, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәт турында күзаллаулар) белән таныштыру. Хезмәткә уңай караш тәрбияләү.

**3. Танып белү.**

Балаларның туган як табигате, өлкәннәр хезмәте, ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, экологик бәйләнешләрне күрә белү мөмкинлекләрен үстерү

**4. Нәфис –нәфәссәти үсеш.**

Музыка әсәрләрен куллану аша балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын баету, үстерү. Балаларда әйләнә-тирәгә карата зәвык тәрбияләү.

**5. Физик үсеш .**

Музыкаль –хәрәкәтле уеннар, сүзле-хәрәкәтле уеннар, аз хәрәкәтле уеннар аша балаларның хәрәкәтчәнлеген арттыру, аларның физик үсешен тәэмин итү.

**2.2. Эш төрләре һәм формалары**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1.Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.

2.Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.

3.Сюжетлы-рольле уеннар;

4.Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).

5.Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).

6.Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.

7.Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.

8.Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.

9.Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).

10.Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.

11.Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.

12.Интерактив уеннар.

**2.3. Программаны гамәлгә кертү һәм үзләштерү буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеген оештыру**

Программаны үзләштерү, тормышка ашыру буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеге көндәлек режимда ике төп модельдә оештырыла: өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге.Белем бирү мәсьәләләренең чишелеше беренче модель кысаларында – өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә –турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге төрендә дә, шулай ук режим вакытларында бара торган белем бирү эшчәнлеге төрендә дә тормышка ашырыла. Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге вакыт белән билгеләнгән шөгыльләрдә түгел, ә бәлки педагог үз теләге белән бала эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, хәрәкәт, танып белү тикшеренү, аралашу, музыкаль, сәнгать, хезмәт эшчәнлеге,шулай ук матур әдәбият уку) оештыру аша яки аларны төрле формалар (проблемалы уен ситуациясе, матур әдәбият уку,күзәтү, хәрәкәтле уен, уен күнегүләре, эксперимент-тикшеренү эшләре, проект эшчәнлеге һ. б.) кулланып берләштергәндә тормышка ашырыла.

**2.4. Ата-аналар белән эш.**

**Төп максатлар һәм бурычлар**.

Гаилә белән конструктив бәйләнешләр үстерү бала шәхесенең тулы үсешен тәэмин итүнең иң мөһим шарты булып тора. Төп максат — тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы үзара мөнәсәбәтләр формалаштыру һәм ата-аналарның компетентлыгын (бала тәрбияләү белән бәйле төрле типтагы социаль-педагогик ситуацияләрне хәл итә алу сәләтен) үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру; ата-аналарның ихтирамлы һәм аңлаулы мөнәсәбәткә, балалар бакчасы тормышында катна- шуга хокукын тәэмин итү.

Ата-аналарга һәм тәрбиячеләргә үзара мөнәсәбәтләрдә субординациядән, монологизмнан арыну, бер-берләрен гаепләү гадәтеннән баш тарту, бер-берләрен үз проблемаларын хәл итү чарасы итеп түгел, ә тигез хокуклы партнерлар, хезмәттәшләр итеп күрә белү зарур.

Балалар бакчасының гаилә белән бәйләнешләренең төп бурычлары:

• педагогларның һәм ата-аналарның балаларны тәрбияләү, өйрәтү-укыту, үсешләренә ирешү, балалар бакчасында һәм гаиләдә төрле эшчәнлекне оешты- ру шартларына кагылышлы төрле мәсьәләләргә карата мөнәсәбәтләрен өйрәтү;

• педагогларны һәм ата-аналарны балалар бакчасында һәм гаиләдә тәр- бияләүнең иң отышлы тәҗрибәсе, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларны гаиләдә һәм җәмгыятьтә тәрбияләүдә туган кыенлыклар белән таныштыру;

• балаларны тәрбияләүнең һәм өйрәтү-укытуның актуаль мәсьәләләре, балалар бакчасының һәм гаиләнең әлеге мәсьәләләрне хәл итү мөмкин- лекләре турында бер-берләренә җиткереп тору.

• балалар бакчасында педагогларның һәм ата-аналарның балалар белән үзара конструктив тәэсир итешүе үсешенә булышлык итүче, эчтәлеге һәм формасы буенча төрле булган хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыру;

• тәрбияләнүчеләрнең гаиләләрен районда (шәһәрдә, өлкәдә, республи- када) оештырыла торган, педагоглар белән бергә уздырылучы чараларда катнашуга җәлеп итү;

• баланың төрле омтылышларына һәм ихтыяҗларына карата игътибар- лы мөнәсәбәт күрсәткән ата-аналарны хуплау, әлеге ихтыяҗларны гаиләдә канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар тудыру.

Гаилә белән ике арадагы бәйләнешләрнең төп юнәлешләре һәм формалары Үзара арадашлык һәм мәгълүмат алмашу Үзара уңышлы бәйләнешләр балалар бакчасы бала гаиләсенең тәрбия мөмкинлекләре белән таныш, ә гаилә баланы тәрбияләү ышанып тапшырыл- ган мәктәпкәчә белем бирү оешмасы турында хәбәрдар булган очракта гына урнашырга мөмкин. Бу бәйләнешләр бала үсешендә бер-беренә кирәкле ярдәм күрсәтергә, тәрбияләүдә гомуми мәсьәләләрне хәл итү өчен булган педагогик ресурсларны тартырга мөмкинлек бирә.

Тәрбия потенциалын ике яклап тирәнтен аңлау өчен әңгәмәләр уздыру, анкеталар төзү, иншалар язу белән бергә махсус оештырылучы социаль-педагогик диагностика; педагогларның тәрбияләнүчеләр гаиләләрендә бу- лулары; балалар бакчасында ачык ишекләр көннәре оештыру; балаларны тәрбияләүче якларның казанышлары һәм кыенлыклары белән танышуга юнәлтелгән төрле җыелыш-очрашулар зур әһәмияткә ия.

Беренче җыелыш-очрашуларның максаты — педагогларның гаиләләр белән һәм тәрбияләнүчеләр гаиләләренең үзара, гаиләләрнең педагоглар белән төрле яклап танышуы. Аралашудагы киртәләрдән арыну өчен, ата- аналарда уңай эмоцияләр тудыручы, педагоглар белән ышанулы мөнәсәбәт- ләр үстерүгә юнәлтелгән махсус алымнар («Дистанция сайла», «Ассоциацияләнгән рәт», «Фотосурәтләр теле», «Туктаусыз сөйләшү» һ.б.) куллану артык булмас. Шундый

җыелышларны ел дәвамында уздыру, һәр җыелышта үз мәсьәләләреңне хәл итә бару урынлы. Тәрбияләүче өлкән кешеләрнең бер-берләренә даими рәвештә балалар- ның балалар бакчасындагы һәм гаиләдәге тормышыннан төрле фактларны, һәм кәефе, эчке һәм тышкы халәте, үзен ничек хис итүе, балалар — өлкәннәр (шул исәптән балалар — ата-аналар) мөнәсәбәтләре турында хәбәр итеп торулары зарур. Әлеге хәбәрләшү турыдан-туры аралашу аша (әңгәмәләр, консульта- цияләр барышында, җыелышларда, конференцияләрдә) яки читләтеп, төрле чыганаклардан — стендлардан, газеталардан, журналлардан (кулдан язып, электрон чыганакта), гаилә календарьларыннан, төрле буклетлардан, интер- нет-сайтлардан (балалар бакчасы, мәгариф идарәсе органнары сайтларын- нан) мәгълүмат алу, шулай ук язышу (шул исәптән электрон чыганаклар аша) нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла.

Стендлар. Стендларда стратегик (күпьеллык) һәм тактик (еллык) мәгълүмат урнаштырыла. Стратегик мәгълүматка балалар бакчасы үсешенең ерак һәм уртача перспективага исәпләнгән максатлары, гамәлгә ашырылучы белем бирү программасы, мәктәпкәчә учреждениенең инновацион проектлары, шулай ук белем бирү буенча өстәмә хезмәтләр турындагы хәбәрләр керә. Тактик мәгълүматлар педагоглар һәм аларның графиклары, көндәлек режим, төркемдә бер елга исәпләнгән тәрбия-белем бирү эшенең бурычлары һәм эчтәлеге турындагы хәбәрләрне үз эченә ала. Тәрбияләүче өлкәннәрнең зур кызыксынуын тудыручы оператив стенд мәгълүматларына төркемдә (балалар бакчасында, районда) көтелә торган яки булып узган вакыйгалар: акцияләр, конкурслар, репетицияләр, күргәзмәләр, очрашулар, уртак проектлар, ял көннәрендәге экскурсияләр һ.б. турындагы хәбәрләр керә. Мәгълүматның бу төре тиз искергәнгә күрә, аны даими рәвештә яңартып торырга кирәк. Стенд мәгълүматлары, әгәр аларны әзерләүдә ата-аналар катнашса, ул мәгълүматлар гаиләнең хәбәрләр җәһәтендәге мәнфәгатьләренә җавап бирсә, алар структура буенча уңышлы урнашсалар һәм эстетик яктан уңыш- лы бизәлсәләр (фотосурәтләр һәм иллюстратив материал кулланыла), ата- аналарда күбрәк кызыксыну уята. Мәгълүмат (бигрәк тә оператив мәгълүмат) тәрбияләүче өлкәннәргә үз вакытында барып ирешсен өчен, аны балалар бакчасы сайтында, шулай ук гаилә календарьларында кабатлау мөһим.

| Ай | Эш төре |
|---|---|
| сентябрь | Ата-аналар җыелышында катнашу (уртанчылар, зурлар, мәктәпкәчә төркеме). |
| | Һәр төркемдә ата-аналар өчен күрсәтмә материалларны яңарту. |
| октябрь | Җыр һәм шигырьләрне өйрәтүдә ата-аналарның ярдәменә таяну. |
| ноябрь | Ата-аналар өчен анкета. |
| декабрь | “Моны белү кызыклы” татарча журналлар уку. |
| | Җыр һәм шигырьләрне өйрәтүдә ата-аналарның ярдәменә таяну. |
| январь | Һәр төркемдә ата-аналар өчен күрсәтмә материалларны яңарту. |
| февраль | “Минем яраткан мультфильм герое”, ата-аналар берлектә рәсем күргәзмәсе. |
| март | Җыр һәм шигырьләрне өйрәтүдә ата-аналарның ярдәменә таяну. |
| | “Нәүрүз” бәйрәменә чакыру. |
| апрель | Г.Тукай әсәрләре буенча кул эшләре күргәзмәсе оештыру “Әкиятләр илендә”. |
| | Ата-аналар өчен анкета. |
| май | “Минем гаиләм” фотокүргәзмә. |

**3. Программаның оештыру бүлеге.**

**3.1. Балаларның үсеше өчен психолого-педагогик шартлар.**

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү программасының нигезен проект алымы тәшкил итә. Проект өч өлештән тора: «Минем өем» (уртанчылар төркеме өчен), «Уйный-уйный үсәбез» (зурлар төркеме өчен), «Мәктәпкә илтә юллар» (мәктәпкәчәәзерлек төркеме өчен). Бу укыту методик комплектлары белән эш эшчәнлектән тыш вакытта индивидуаль эшләнә.

**Уртанчылар төркеме.**

Уртанчы яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә рольле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу яшьтәге балалар кабул ителгән рольдән үзләрен аера башлыйлар. Уен процессында рольләр үзгәрергә мөмкин. Алар үзләре өчен түгел, ә уенны мәгънәле итү өчен уйный башлыйлар. Уендагы һәм чынбарлыктагы мөнәсәбәтләр аерымлана.

Зиһенгә алу сәләте күбрәк үсеш ала. Балалар теге яки бу предметка охшаган форманы атый беләләр. Алар катлаулы объектларда гади формаларны аерып күрсәтә һәм гади формалардан катлаулы объектлар барлыкка китерә алалар. Балалар предмет төркемнәрен сенсорик билгеләре-зурлыгы, төсе буенча тәртипкә салырга, биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга сәләтле. Хәтер күләме үсә. Балалар 7-8 предметның исемен истә калдыра алалар. Истә калдыру мөмкинлекләре үсә. Алар олылар тапшырган эшне истә калдыралар. Кечкенә шигырьләрне ятлый алалар.

Тасвирлы фикерләү сәләте үсә башлый. Балалар катлаулы булмаган мәсьәләләрне чишүдә гади схемалаштырылган сүрәтләр кулланалар. Алар схема буенча төзи, лабиринтлы мәсьәләләрне чишә алалар. Алдан күрә белү сәләте үсә.

Күз алдына китерү, уйлап чыгару сәләте үсә. Оригинальлек һәм ирекле булу кебек сыйфатлар формалаша. Балалар мөстәкыйль рәвештә бирелгән темага зур булмаган әкият уйлап чыгара алалар.

Игътибарлылык сәләте үсә. Бала 15-20 минут дәвамында игътибарын туплап эшли алырга сәләтле. Ул нинди булса да эш эшләгәндә катлаулы булмаган шартны хәтерендә тотып тора ала.

Авазлар әйтелеше һәм дикция яхшыра. Сөйләм балаларның активлыкларын үстерә. Алар хайван тавышлары чыгаралар. Теге яки бу персонажның сөйләмен интонация белән аерып күрсәтә алалар. Сөйләмнең ритмик төзелеше, рифмасы игътибарга лаек. Сөйләмнең грамматик ягы үсеш ала. Балалар грамматик кагыйдәләр нигезендә яңа сүзләр уйлап чыгару белән мавыгалар. Бер-берсе белән аралашканда балаларның сөйләме ситуациягә бәйле, ә олылар белән аралашканда ситуациягә бәйләнмәгән була.

Бала белән олыларның аралашу эчтәлеге үзгәрә. Ул бала эләккән конкрет ситуациядән читкә тайпыла. Аралашу процессында алган мәгълүматлар бик үк аңлашылып бетмәсәләр дә, балада кызыксыну уяталар.

Бала өлкәннәрнең үзен ихтирам итүләрен тели, мактау сүзе аның өчен бик зур әһәмияткә ия була бара. Бу баланың артык үпкәләүчән булуына китерә. Ярышу, көндәшлек барлыкка килә. Ярышу үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен әһәмиятле.

Бу яшьнең төп казанышлары: уен эшчәнлеге үсү; рольле һәм тормышчан үзара бәйләнешләр барлыкка килү; сурәтләү эшчәнлеге үсү; үзең уйлап конструкцияләү; планлаштыру, зиһенгә алу сәләте камилләшү, образлы, хыялый фикерләү, танып белүдә мин-минлек; хәтер, игътибар, сөйләм, дәлилли белү сәләте үсү, олыларның хөрмәтенә ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, ярышу кебек сыйфатлар барлыкка килү, *Мин* образының үсүе белән характерлана.

**Зурлар төркеме.**

Алтынчы яшьтәге балалар уен башланганчы рольләрне бүлешә һәм эш-гамәлләрне яраклаштырып төзи беләләр. Уендагы мөнәсәбәтләр эчтәлек һәм интонация ягыннан алган рольгә туры килүче сөйләм белән үрелеп бара. Балаларның реаль мәнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерыла. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм олыларның төрле эшчәнлекләрдәге буйсынучанлык позициясен аңлый башлыйлар.

Төсне, форма һәм зурлыкны, предметларның төзелешен аңлау, кабул итү камилләшә бара.

Балаларның күзаллаулары системалаштырыла. Балалар төп төсләр һәм аларның төсмерләрен генә түгел, ә арадаш төсләрнең төсмерләрен дә, шулай ук турыпочмак, овал, өчпочмакларның формаларын да аералар һәм атыйлар. Бер дистә предметны зурлыклары буенча рәткә тезеп куя алалар.

Зурлар төркемендә образлы фикер йөртү үсеше дәвам итә. Балалар күрсәтмә планда мәсъәләне чишәргә генә түгел, хәттә объектны үзгәртергә, объектларның нинди эзлеклелектә бер-берсе белән бәйләнешкә керү мөмкинлекләрен күрсәтергә һ.б. да сәләтле.

Бу яшьтә уйләп чыгару сәләте үсү балаларга шактый оригиналь һәм эзлекле киңәйтелгән хикәяләр уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Балаларның әлеге сәләте бары тик бу юнәлештә махсус эш алып барганда гына актив рәвештә үсәчәк.

Балаларның игътибар тотрыклылыгы үсә. Алар шулай ук игътибарларын кирәк юнәлешкә бора һәм башкага күчерә ала башлыйлар. Ирексез игътибардан аңлы игътибарга күчү күзәтелә.

Сөйләм, шул исәптән аның аваз ягы камилләшү дәвам итә. Балалар сызгырулы, чыжылдаулы һәм сонор авазларны дөрес әйтә башлыйлар. Шигырьләр укыганда,сюжетлы-рольле уеннар вакытында һәм көндәлек тормышта фонематик ишетү сәләте, сөйләмнең сәнгатьлелеге үсә, грамматик төзелеше камилләшә. Балалар барлык сүз төркемнәрен кулланалар, сүз уйлап чыгару белән актив шөгыльләнәләр. Сүз байлыклары арта. Синоним белән антонимнар актив кулланышка керә. Бәйләнешле сөйләм үсә. Балалар эчтәлекне дә, рәсемнәр буенча да иң мөһимен генә түгел, ә детальләрне дә кертеп сөйли ала башлыйлар.

Бу яшьнең казанышлары: уен эшчәнлегендә рольләр булешү; уен пространствосын төзи белү;югары нәтиҗәлелеге белән аерылып торган рәсем эшчәнлегенең алга таба үсеше; конструкцияләүдә үрнәкне карап гомумиләштерә белү. Зиһенгә алу объектларның катлаулы формаларын анализлау белән характерлана; фикерләү чараларын (схемалы,комплекслы күзаллаулар, циклы үзгәрешләр турында күзаллаулар) үзләштерү белән бергә фикер йөртү сәләте үсә, гомумиләштерү күнекмәләре, уйлап чыгару сәләте, тотрыклы игътибар, сөйләм, *Мин* образы үсә.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме.**

Сюжетлы-рольле уеннарда җиденче яшькә чыккан балалар өлкәннәрнең әһәмиятле тормыш вакыйгаларын чагылдыручы катлаулы мөнәсәбәтләрен үзләштерә башлыйлар.

Уен элементлары катлаулана, олы кешегә һәрвакытта да ачылып бетми торган мәгънә ала бара. Уен пространствосы катлаулана. Балалар бергә уйнәган иптәшләренең үз-үзләрен тотышын барлык уен пространствосы буйлап күздән ычкындырмаска һәм кирәк вакытта уенның урынына бәйле рәвештә үстерергә сәләтлеләр.

Кабул итү сәләте үсә, ләкин балалар һәрвакытта да әйбернең берничә төрле билгесен бер юлы исәпкә алып бетерә алмыйлар. Образлы фикерләү сәләте үсә, ләкин үлчәү мөнәсәбәтләрен кабаттан торгызу бала өчен авырлык тудыра.

Гомумиләштерү һәм фикер йөртү күнекмәләре үсү дәвам итә, ләкин алар күп очракта ситуациянең күрсәтмә билгеләре белән чикләнәләр.

Уйлап чыгару сәләте үсә, ләкин бу зурлар төркеме белән чагыштырганда, шактый түбән. Моны төрле йогынтылар белән, бигрәк тә балаларның образларын бертөрлегә әйләндерүче массакүләм мәгълүмат чаралары йогынтысы белән аңлатырга була.

Балаларның игътибарлылыгы арта бара. Алар кайбер эшчәнлек вакытында 30 ар минут игътибарларын туплап утыра алалар.

Балаларның сөйләме, аның аваз ягы, грамматик төзелеше, лексикасы үсә. Бәйләнешле сөйләмнәре дә шомара. Сөйләмнең бу яшьтә формалаша торган гомумиләштерү характеры да чагыла. Балалар актив рәвештә гомумиләштерүче исемнәр, синонимнар, антонимнар, сыйфатлар һ.б. кулллана башлыйлар. Дөрес оештырылган белем бирү процессы нәтиҗәсендә балаларда диалогик сөйләмнең кайбер төрләре үсә.

Балалар кешелек культурасының аерылгысыз өлеше булган әйберләр дөньясы белән танышалар; кешеләр белән позитив аралашу формаларын үзләштерәләр; укучы позицисе формалаша.

Мәктәпкәчә яшьнең ахырына бала шактый югары дәрәҗәдәге танып белүчәнлеккә һәм шәхес буларак үсешкә ия була. Бу сыйфатлар аның киләчәктә мәктәптә уңышлы укуын тәэмин итә.

**3.2. Предметлы-үстерелешле әйләнә тирәлек мохите.**

Балалар бакчасында белем бирү мохите баланың мәктәпкәчә балачагын тулы кыйммәтле уздыру өчен кирәкле махсус шартларны таләп итә. Предметлы үсеш мохите дигәндә баланың танып белүдә, аралашуда, хезмәт, тулаем физик һәм рухи үсеш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җайлаштырылган, оештыру ягыннан формалаштырылган һәм предметлар белән тулыландырылган билгеле бер тирәлек аңлана. Үсешкә булышлык итүче предметлы мохитне заманча күзаллау баланың актив эшчәнлеген тәэмин итүне, аның субъектив позициясен формалаштыруны, иҗади сәләтләрен, мөмкинлекләрен барлык чаралар белән үстерүне үз эченә ала. Мохит оештыруга төп таләпләр

Мәктәпкәчә оешманың үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохите:

- тулы эчтәлекле, үсешкә илтүчән;
- үзгәрүчән;
- күп функцияле;
- вариатив;
- аңлаешлы;
- куркынычсызлыкны тәэмин итүчән;
- сәламәтлекне саклаучан;
- эстетик җәлеп итүчән булырга тиеш.

3.4. **Материал-техник база.**

**Материаль - техник яктан тәэмин ителеш**

| | | |
|---|---|---|
| Татар теле кабинеты | Белем бирү эшчәнлеге, индивидуаль, коррекцион эш, ата-аналар, педагоглар өчен консультацияләр , ачык эшчәнлекләр . | Зурлар һәм балалар өчен өстәлләр, урындыклар, принтер, экран, ноутбук, магнитофон, уенчыклар, дидактик, интерактив уеннар, тематик папкалар, укыту -методик комплект (күрсәтмә һәм таратма материаллар, аудио- видео дисклар, маскалар),ТР һәм РФ символикасы. |

**Дидактик һәм үстерешле уеннар:** “Бу кем?”, “Бу нәрсә?”, “Әйе, юк”, “Кем юк?”, “Нәрсә юк?”, “Уйна!”, “Бир эле!”, “Ничә?”, “Нинди?” “Нәрсә кирәк?”, “Нәрсә бар?”, “Нишли, нишлисең?”, “Бу өйдә кем яши?”, “Дөрес күрсәт!”, “Бармак уены”, “Кибеттә нәрсә бар?”,”Мәктәптә нәрсә бар?”, “Кафеда нәрсә бар?”, “Телефоннан сөйләшү”.

**Уртанчылар төркеменең «Минем өем» укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар.**

| | | |
|---|---|---|
| 1. А4 форматында күрсәтмә рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе 1 данә |
| | Зур уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина – пычрак уенчыклар. | Һәрберсе 1 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: «Куян өйгә керә, өйдә аю утыра». «Куян өйдән чыга, саубуллаша». | Һәрберсе 1 данә |

| | | |
|---|---|---|
| | Рәсемнәр: 1 куян, 2 куян, 3 куян, 4 куян, 5 куян;<br>1 аю, 2 аю, 3 аю, 4 аю, 5 аю;<br>1 курчак, 2 курчак, 3 курчак, 4 курчак, 5 курчак;<br>1 туп, 2 туп, 3 туп, 4 туп, 5 туп;<br>1 машина, 2 машина, 3 машина, 4 машина, 5 машина;<br>1 песи, 2 песи, 3 песи, 4 песи, 5 песи;<br>1 эт, 2 эт, 3 эт, 4 эт, 5 эт. | Һәрберсе 1 данә |
| 2. А3 форматында өй рәсеме. | Өй макеты | 1 данә |
| 3. А5 форматында таратма рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе 15 данә |
| 4. Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар. | Битлекләр: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, куян, аю, песи, эт. | Һәрберсе 15 данә |
| | Бармак уеннары өчен атрибутлар: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт Акбай, песи Мияу, аю, куян. | Һәрберсе 15 данә |

**Зурлар төркеменең «Уйный-уйный үсәбез» укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар.**

| | | |
|---|---|---|
| 1. Күрсәтмә рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Малай, кыз рәсемнәр («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
